МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

04.06.2021 г.Казань № 395

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2021 елның 24 июнендә 7751 номеры белән теркәлде

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәреш-ләр кертү турында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к  б и р ә м:

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү һәм
социаль яклау министрлыгының
04.06.2021 №395 боерыгы белән расланды

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Тәрбиягә алынганнарын да исәпкә алып, 18 яшькә кадәр өч һәм аннан күбрәк баласы булган гаиләләргә субсидияләр билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 8 декабрендәге 675 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 06.06.2016 №315, 28.11.2016 №668, 08.06.2017 №349, 07.05.2018 №350, 18.09.2018 №858, 22.04.2019 №290, 28.08.2019 №655, 07.11.2019 №933, 28.02.2020 №135, 13.07.2020 №499, 09.10.2020 №717 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Тәрбиягә алынганнарын да исәпкә алып, 18 яшькә кадәр өч һәм аннан күбрәк баласы булган гаиләләргә субсидияләр билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

1 бүлектә:

1.2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гомуми белем бирү оешмаларында укучы, 6 яшькә кадәрге баланың һәм, тәрбиягә алганнарын да кертеп, 18 яшен тутырмаган өч һәм аннан күбрәк балалы гаиләләрдән һөнәри белем бирү оешмаларында укучы студентларның бала (балалар) үзләре белән бергә яши торган әти-әнисе, аларның законлы вәкилләре яки ышаныч нигезендә алар тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар.»;

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Дәүләт хезмәте «Республикасы матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе тарафыннан мөрәҗәгать итүченең яшәгән урыны буенча Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында Үзәк бүлекчәсендә (алга таба – Үзәк бүлекчәсе) күрсәтелә.»;

1.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.6. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыны – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы шәһәр (авыл) җирлегендә яки шәһәр округында булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

Идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы (алга таба –

ИАБС) – электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итүче инфраструктурада Идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы;

техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата).

Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) дигәндә дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать турында сүз бара («Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 1 пункты (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон).»;

2 бүлектә:

2.2 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында Үзәк бүлекчәсе йөзендә «Республикасы матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

2.4 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү бурычларны түләп бетергәнчегә кадәр туктатыла, ләкин дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән көннән алып 90 көннән дә артыграк булмаган чорга гына.»;

2.5 пунктта:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Социаль түләүләр алу өчен федераль законнар нигезендә банкта яки башка кредит учреждениесендә ачылган шәхси счет реквизитларын күрсәтеп (компенсацияне банк аша алган очракта), субсидия билгеләү турында гариза:

әлеге Регламентка 1-2 нче кушымталар нигезендә кәгазьдә документ формасында;

- Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, әлеге пункт таләпләренә туры китереп имзаланган электрон формада (гаризаның электрон формасына тиешле белешмәләрне кертү юлы белән тутырыла);

2) чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан бирелгән тууны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемә күчермәсе;

3) гражданлык хәле актларын теркәү органнары яисә Россия Федерациясе консуллык учреждениеләре тарафыннан бирелгән уллыкка алу турында таныклык күчермәсе.

Гомуми белем бирү оешмалары укучыларының, һөнәри белем бирү оешмалары

студентларының ата-аналары (законлы вәкилләре) өстәмә рәвештә, чит ил дәүләте территориясендә бирелгән, тәмамлап чыгу датасын күрсәтеп, белем алуга бәйле документ күчермәсен һәм аның нотариаль таныкланган рус теленә тәрҗемәсе күчермәсен тапшыра.

Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар өстәмә рәвештә мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрендә эш итүен раслый торган документларны тапшыра.

Гаризаны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша бирелгән очракта, әлеге пунктта күрсәтелгән документларның электрон үрнәкләре яки электрон формадагы документлар мондый документларны булдыру һәм имзалау өчен вәкаләтле булган затлар, шул исәптән нотариуслар тарафыннан да, «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланган булырга тиеш.

Документлар һәм белешмәләр мөрәҗәгать итүче тарафыннан тиешле оешмаларда – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алына.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм Үзәк бүлекчәсе белгече тарафыннан таныклана.

Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану буенча гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Үзәк бүлекчәсенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гаризаны шулай ук Үзәк бүлекчәсендә белгеч шәхсән кабул иткәндә электрон рәвештә тутырырга мөмкин, аны мөрәҗәгать итүче, электрон рәвештә укыла торган имзадан файдаланып, имзалый.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе буенча тапшырыла (җибәрелә) ала:

1) Үзәк бүлекчәсендә кәгазьдә;

2) Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша электрон формада;

3) гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән Интернет челтәре аша.

Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.

Гаризаны һәм кирәкле документларны гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да җибәргән очракта, гариза һәм электрон документ формасында документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре ниге-

зендә имзаланырга (расланган булырга) тиеш.

Мөрәҗәгать итүче гаризаны һәм кирәкле документларны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәргән очракта, гаризаны гади электрон имза белән имзалый.

Гади электрон имзаны алу өчен, мөрәҗәгать итүчегә ИАБС системасында теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр исәпкә алу язуын расларга кирәк.

Зеленодольск шәһәрендә яшәүчеләр өстәмә рәвештә гаризаны Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша җибәрә ала, аларның адреслары Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында урнаштырылган»;

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәтүгә карата таләпләр турында» 2016 елның 26 мартындагы карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәтүгә карата таләпләр (алга таба – Таләпләр)» сүзләрен өстәргә;

2.6 пунктта:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша түбәндәге мәгълүматлар алына:

балалар тууын дәүләт теркәвенә алу турында (вәкаләтле органнарда);

баланы гаиләгә тәрбиягә тапшыру турында (җирле үзидарә органнарында);

ата-аналык хокукыннан мәхрүм итү турында (җирле үзидарә органнарында);

мөрәҗәгать итүче белән аның даими яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында (вәкаләтле органнарда);

чыгарылу датасын күрсәтеп, баланы гомуми белем бирү оешмасында, һөнәри белем бирү оешмасында укыту турында (вәкаләтле органнарда);

хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында (Россия Федерациясе Пенсия фондында);

салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле бурычларның булуы турында (вәкаләтле оешмаларда).

Мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яки Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша мөрәҗәгать иткән очракта, өстәмә рәвештә ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча мөрәҗәгать итүченең паспортының чынлыгын раслау турында мәгълүмат алына (Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгында).

Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.

Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

Үзәк бүлекчәсе мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документлар һәм мәгълүмат тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торганын да, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны тапшыруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) төгәл булмавы турында күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүмат тапшыруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә электрон рәвешләре элегрәк таныкланган документларны һәм мәгълүматларны кәгазьдә тапшыруны, мондый документларга тамгалар кертү яки аларны бетерү дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан тыш һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш;»;

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасына «Таләпләр» сүзен өстәргә;

2.7 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасының 1 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

2.7 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталында урнаштырылган, дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүматка туры китереп тапшырылган булсалар, гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.»;

2.7 пунктта «Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасына «Таләпләр» сүзен өстәргә;

2.8 пунктта:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычы булуы дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигез булып тора.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

шушы Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелмәгән затның мөрәҗәгать итүе;

әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның тапшы-

рылмавы;

мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча субсидия билгеләү турында сорап мөрәҗәгать иткән көннән соң 90 көн эчендә җайга салынмаган булса.

Әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталда бастырып чыгарылган мәгълүмат нигезендә тапшырылган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту тыела.»;

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында «4.7, 5.7» саннарын «4.9, 5.9» саннарына алмаштырырга;

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасына «Таләпләр» сүзен өстәргә;

2.16 пунктта:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталында һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге 7.2 пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан файдаланып тапшырырга;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын бәяләргә;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

е) Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Үзәк бүлекчәсе, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчеләрне Үзәк бүлекчәсенә кабул итүгә язу (алга таба – язу) Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Үзәк бүлекчәсе телефоны аша гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчегә Үзәк бүлекчәсендә билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә буш булган теләсә нинди кабул итү датасына һәм вакытына язылу мөмкинлеге бирелә.

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен, мөрәҗәгать итүчегә система аша соралган мәгълүматларны күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилиясен, исемен һәм атасының исемен (булган очракта);

телефон номерын;

электрон почта адресын (ихтыярына карап);

кабул итүнең теләнгән датасын һәм вакытын.

Алдан язылганда мөрәҗәгать итүче күрсәткән белешмәләр мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул иткәндә тапшырылган документларга туры килмәгән очракта, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Алдан язылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә талон-раслама чыгартып алу мөмкинлеге бирелә. Әгәр мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын күрсәтсә, күрсәтелгән адреска шулай ук кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Алдан язылганда билгеләнгән кабул итү вакыты башланып, 15 минут узганнан соң да килмәгән очракта, мөрәҗәгать итүчегә алдан язылуның гамәлдән чыгарылуы турында зарури тәртиптә мәгълүмат җиткерелә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тарта ала.

Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификацияләүне һәм аутентификацияләүне узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен алдан ук билгеләп куелырга тиешле кирәкле вакыт озынлыгын исәпләүдә кирәкле белешмәләрне тапшырудан тыш, мөрәҗәгать итүчедән башка гамәлләр башкаруны таләп итү тыела.

Гариза Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яки Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша җибәрелергә мөмкин.

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яки Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша гариза биргәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе электрон формада бирелә»;

2.16 пунктта «Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасына «Таләпләр» сүзен өстәргә;

3.1.1 пунктчаның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия билгеләү (билгеләүдән баш тарту), дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңартып җибәрү) турында карар әзерләү;»;

3.3.1 пунктчасының дүртенче абзацын түбәндәге төзәтмәсендә бәян итәргә:

«3.3.1. Мөрәҗәгать итүче субсидия билгеләү турында гаризаны Үзәк бүлекчәсенә, әлеге Регламентның 2.5 пунктына туры китереп, документларны теркәп тапшыра.

Гариза һәм документларның Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган күчермәләре почта аша җибәрелергә мөмкин.

Мөрәҗәгать итүче, гаризаны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша электрон формада тапшыру өчен, түбәндәге гамәл-

ләрне башкара:

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында авторизацияләү уза;

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында электрон гариза формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яки электрон документ үрнәкләрен электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга билгели);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле тамга билгели);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза формасындагы тиешле төймәгә баса);

электрон гариза әлеге Регламентның 2.5 пункты таләпләре нигезендә имзалана;

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Мөрәҗәгать итүчеләр гаризаны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яки Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша җибәрә ала.

Үзәк бүлекчәсе хезмәткәре дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган, әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булу-булмавын тикшерә.

Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булмаса, Үзәк бүлекчәсе белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гаризаны кабул итә һәм мөрәҗәгатьләрне теркәү журналында (3 нче кушымта) терки;

гаризаны һәм документларны кабул итү датасы, кергәндә беркетелгән номеры (мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта) турында тамгалап, мөрәҗәгать итүчегә язу тапшыра, гариза почта буенча һәм (яки), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелгән очракта, гаризаны теркәү датасы һәм алынганда беркетелгән номеры турында белдерү җибәрә яисә Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына гаризаны теркәү турында белдерү җибәрә (гариза Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яки Татарстан Республикасы Электрон Инфоматлары аша җибәрелгән очракта).

Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булган очракта (мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткәндә), Үзәк бүлекчәсе белгече мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре турында телдән хәбәр итә һәм, документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, барлык документларны аңа кайтарып бирә. Гаризаны һәм документларны почта аша һәм (яисә), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән алганда, Үзәк бүлекчәсе белгече гаризаны

һәм документларны, документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту сәбәпләрен язмача аңлатып, кайтарып бирә.

Гаризаны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша биргән очракта, гаризаны теркәүдән баш тарту турында белдерү мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетына җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә башкарыла:

шәхсән кабул иткәндә яисә гариза һәм документлар почта аша килгәндә – гариза һәм документлар алынган көнне;

гариза һәм документлар Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша килгәндә яки почта аша, шул исәптән «Интернет» челтәре аша», электрон почта буенча электрон документлар рәвешендә килгәндә, – гариза һәм документлар Үзәк бүлекчәсенә килгән көнне яисә, гариза һәм документлар Үзәк бүлекчәсенең эш вакыты тәмамлангач килгән очракта, киләсе эш көнендә. Гариза Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша килгәндә яки почта аша, шул исәптән «Интернет» челтәре аша», электрон почта буенча электрон документлар рәвешендә ял яки эшләми торган бәйрәм көннәрендә килгән очракта, – Үзәк бүлекчәсенең ял яки эшләми торган бәйрәм көненнән соң килүче беренче эш көнендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән документлар, гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында теркәү язуы, язу яисә мөрәҗәгать итүчегә кайтарып бирелгән документлар, мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән баш тарту турында телдән (язмача) белдерү.

3.4.1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Үзәк бүлекчәсе белгече электрон рәвештә түбәндәге белешмәләрне ала:

балалар тууын дәүләт теркәвенә алу турында – вәкаләтле органнан;

чыгарылу датасын күрсәтеп, баланы гомуми белем бирү оешмасында, һөнәри белем бирү оешмасында укыту турында – вәкаләтле органнан;

Россия Федерациясе чикләрендә Россия Федерациясе гражданинының яшәгән яки торган урыны буенча теркәлгән яки теркәлмәгән булуы турында – вәкаләтле органнан.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза алынган көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: вәкаләтле органнардан алынган белешмәләр.»;

3.4.2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.2. Субсидия билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр Үзәк бүлекчәсендә булмаса, Үзәк бүлекчәсе белгече электрон рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәге белешмәләрне бирү турында гарызнамәләр җибәрә:

балалар тууын дәүләт теркәвенә алу турында – вәкаләтле органнарда;

баланы гаиләгә тәрбиягә тапшыру турында – җирле үзидарә органнарына;

ата-аналык хокукыннан мәхрүм итү турында – җирле үзидарә органнарына;

мөрәҗәгать итүче белән аның даими яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында – вәкаләтле органга;

мөрәҗәгать итүче паспортының чын булуын раслау турында – Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша яки Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте Инфоматлары аша мөрәҗәгать иткән очракта – Татарстан Республкиасы буенча Эчке эшләр министрлыгына;

Россия Федерациясе Пенсия фондына – хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында;

салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле бурычларның булуы (булмавы) турында – вәкаләтле органга.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: вәкаләтле органнарга җибәрелгән мәгълүматлар бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр.»;

3.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Субсидия билгеләү (билгеләүдән баш тарту), дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңартып җибәрү) турында карар әзерләү

3.5.1. Үзәк бүлекчәсе белгече әлеге Регламентның 3.4.1 пунктчасында күрсәтелгән, алынган белешмәләр һәм әлеге Регламентның 3.4.2 пунктчасында күрсәтелгән, ведомствоара хезмәттәшлек органнарыннан законнарда билгеләнгән срокларда алынган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документлар нигезендә түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиле яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән зат вәкаләтләрен тикшерә;

әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре булу-булмавын тикшерә;

дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен кирәкле, әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булу-булмавын тикшерә;

әлеге Регламентка 4 нче һәм 5 нче кушымталары нигезендәге электрон рәвештәге формалар буенча субсидия билгеләү (билгеләүдән баш тарту) яисә дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында карар проектын рәсмиләштерә;

субсидия билгеләү (билгеләүдән баш тарту) яки дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында карар проектын электрон рәвештә Үзәк бүлекчәсе җитәкчесенә имзалау өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар рәсми мөрәҗәгатьләргә җаваплар алынган көннән ике эш көне эчендә, әмма гаризаны теркәгәннән соң җиде эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: субсидия билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында яки электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында электрон рәвештәге карар проекты.

3.5.2. Үзәк бүлекчәсе җитәкчесе субсидия билгеләү (билгеләүдән баш тарту) яки дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында электрон рәвештәге карар проектын карый һәм, электрон санлы имза белән имзалап, Үзәк бүлекчәсе белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура документларны субсидия билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар проекты җибәрелгән көннән башлап

бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган һәм Үзәк бүлекчәсе белгеченә җибәрелгән субсидия билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында яки дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында карар.

3.5.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында белдерү

Үзәк бүлекчәсе белгече дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында кабул ителгән карар турында мөрәҗәгать итүче тарафыннан гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресына язмача формада, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында, телефонга СМС-хәбәр җибәреп) хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турындагы карар имзаланган көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында кабул ителгән карар турында хәбәр итү.

3.5.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү яки субсидия билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү

3.5.4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү туктатып торылган вакыт эчендә мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмавы турында белешмәләр алынса яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелгән бурычны җайга салуны раслый торган документлар тапшырылган очракта, Үзәк бүлекчәсе белгече:

әлеге Регламентка 8 нче һәм 9 нчы кушымталар нигезендәге форма буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү турында карар проектын электрон рәвештә рәсмиләштерә;

әлеге Регламентка 4 нче һәм 5 нче кушымталар нигезендәге форма буенча субсидия билгеләү турында карар проектын рәсмиләштерә;

дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү һәм субсидия билгеләү турындагы карар проектларын Үзәк бүлекчәсе җитәкчесенә имзалу өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычның булмавы яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан бурычларны җайга салуны раслый торган документлар тапшырылганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

3.5.4.2. Мөрәҗәгать итүче Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычларны җайга салмаган очракта, гариза биргән көннән соң 90 көн узгач, Үзәк бүлекчәсе белгече субсидия билгеләүдән баш тарту турында карар проектын әзерли һәм Үзәк бүлекчәсе җитәкчесенә имзалау өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны биргән көннән соң 90 көн узгач, аннан соңгы бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: субсидия билгеләүдән баш тарту турында карар проекты.

3.5.4.3. Үзәк бүлекчәсе җитәкчесе дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү турында һәм субсидия билгеләү турында карар проектларын яисә субсидия билгеләүдән баш тарту турында карар проектын карый һәм электрон санлы имза белән имзалый һәм Үзәк бүлекчәсе белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү турында һәм субсидия билгеләү турындагы карар проектлары яисә субсидия билгеләүдән баш тарту турындагы карар проекты имзаланганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Үзәк бүлекчәсе җитәкчесе тарафыннан имзаланган дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү һәм субсидия билгеләү яки субсидия билгеләүдән баш тарту турында карарлар.

3.5.4.4. Үзәк бүлекчәсе белгече дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү турында кабул ителгән карар турында мөрәҗәгать итүче тарафыннан гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресына язмача формада, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында, телефонга СМС-хәбәр җибәреп) хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү турындагы карар имзаланган көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү турында кабул ителгән карар турында хәбәр итү.»;

3.6 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Үзәк бүлекчәсе белгече мөрәҗәгать итүчегә мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелгән ысул белән (субсидия билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар күчермәсен почта адресына язмача формада, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында, телефонга СМС-хәбәр җибәреп яисә Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына юллап) субсидия билгеләнүе (субсидия билгеләүдән баш тартылуы) турында хәбәр итә.

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә субсидия билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар турында хәбәр итү, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына субсидия билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар җибәрү.»;

3.8 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Техник хатаны төзәтү әлеге Регламентка 6 нчы һәм 7 нче кушымталардагы форма буенча, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңартып җибәрү) турындагы документны яки мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак тапшырылган, техник хатасы булган документны (әгәр андый документлар бирелгән булса) теркәп, мөрәҗәгать итүче тарафыннан гариза тапшырылган очракта гамәлгә ашырыла.»;

3.8.1 пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңартып җибәрү) турындагы карарны яисә субсидия билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында электрон рәвештәге карарны үзгәртеп рәсмиләштерә;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңартып җибәрү) турында үзгәртеп

рәсмиләштерелгән карар проектын яисә субсидия билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турындагы карар проектын электрон рәвештә Үзәк бүлекчәсе җитәкчесенә имзалау өчен җибәрә.»;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән, теркәлгән гариза, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңартып җибәрү) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар яисә субсидия билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында электрон рәвештә Үзәк бүлекчәсе җитәкчесенә имзалау өчен җибәрелгән карар.»;

3.8.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.8.2. Үзәк бүлекчәсе җитәкчесе электрон цифрлы имза белән дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңартып җибәрү) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карарны яисә субсидия билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турындагы карарны имзалый һәм аны Үзәк бүлекчәсе белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура карар проекты имза салу өчен җибәрелгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Үзәк бүлекчәсе җитәкчесе тарафыннан имзаланган дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңартып җибәрү) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар яисә субсидия билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар.»;

3.8.3 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.8.3. Үзәк бүлекчәсе белгече дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңартып җибәрү) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар турында яисә субсидия билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турындагы карар турында мөрәҗәгать итүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән (дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңартып җибәрү) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар турында яисә субсидия билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турындагы карар күчермәсен почта адресы буенча язмача, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында, телефонга смс-хәбәр итеп, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына юллап) хәбәр итә.»;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңартып җибәрү) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар яки субсидия билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар турында хәбәр итү, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңартып җибәрү) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карарны яки субсидия билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар күчермәсен Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына юллау.».

5.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.4. Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш.

Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы унбиш эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтә торган органдагы вазыйфаи затның (учреждение хезмәткәренең) мөрәҗәгать итү-

чедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән чоры бозылганда, аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.»;

Регламентка 1 нче кушымтаның нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тәрбиягә алынганнарын да кертеп, 18 яше тулмаган өч һәм аннан күбрәк балалы гаиләләрдәге балаларга субсидияләр билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта»;

Регламентка 2 нче кушымтаның нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тәрбиягә алынганнарын да кертеп, 18 яше тулмаган өч һәм аннан күбрәк балалы гаиләләрдәге балаларга субсидияләр билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта»;

Регламентка 3 нче кушымтаның нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тәрбиягә алынганнарын да кертеп, 18 яше тулмаган өч һәм аннан күбрәк балалы гаиләләрдәге балаларга субсидияләр билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта»;

Регламентка 4 нче кушымтаның нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тәрбиягә алынганнарын да кертеп, 18 яше тулмаган өч һәм аннан күбрәк балалы гаиләләрдәге балаларга субсидияләр билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта»;

Регламентка 5 нче кушымтаның нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тәрбиягә алынганнарын да кертеп, 18 яше тулмаган өч һәм аннан күбрәк балалы гаиләләрдәге балаларга субсидияләр билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта»;

Регламентка 6 нчы кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тәрбиягә алынганнарын да кертеп, 18 яше тулмаган өч һәм аннан күбрәк балалы гаиләләрдәге балаларга субсидияләр билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 6 нчы кушымта

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №___ бүлекчәсенә

______________________________________

муниципаль районында (шәһәр округында)

Техник хатаны төзәтү турында гариза

Мин,____________________________________________________________________,

Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) яши торган адрес

______________________________________________________________________________

(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индексын күрсәтеп, телефоны, электрон адресы)

______________________________________________________________________________.

(мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклаучы документ аталышы, аның сериясе, номеры, бирелү

______________________________________________________________________________,

датасы, документны биргән орган атамасы)

техник хатаны төзәтүне сорыйм ________________________________________

(кирәклесе астына сызарга):

______________________ билгеләү (билгеләүдән баш тарту) буенча дәүләт хезмәте

(түләүнең аталышы)

күрсәтүне туктатып тору (яңартып җибәрү) турында ___________ №_______ карарда

(карар датасы) (карар номеры)

җибәрелгән.

______________________________________________________________________________.

(карар реквизитлары, бирелү датасы)

